Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче Яңа поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче Яңа поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октяберендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юллар, тротуарлар төзү буенча эшләр башкару, юлларны ремонтлау,вак таш һәм асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре; ясалма юл тигезсезлекләрен төзү буенча эшләр башкару (ИДН һәм билгеләр алу һәм урнаштыру);;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (технологик тоташтыру, электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)ремонтлау;;

- урам яктырту җайланмасы (СИП кабель салу); )

- торак пункт территориясен төзекләндерү (яңа Бистәсе паркының "Хәтер" бакчасы территориясен төзекләндерү,юлларны реконструкцияләү, урам яктырткычларын, кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, койма урнаштыру);».

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 27 октяберендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа поселогы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юллар, тротуарлар төзү буенча эшләр башкару, юлларны ремонтлау,вак таш һәм асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре; ясалма юл тигезсезлекләрен төзү буенча эшләр башкару (ИДН һәм билгеләр алу һәм урнаштыру);;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (технологик тоташтыру, электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)ремонтлау;;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (яңа Бистәсе паркының "Хәтер" бакчасы территориясен төзекләндерү,юлларны реконструкцияләү, урам яктырткычларын, кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, койма урнаштыру);».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Әҗмәкәй авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы Г.Т.Хөсәенова